| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА СЕЛЕНГУШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СӘЛӘНГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ<br>2 ноябрь 2020 ел | КАРАР<br>№ 2 |
|---|---|

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 14 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Сәләнгеш авылы, Гагарин урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Сәләнгеш авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында Калинин урамы буенча 4-43 нче йорттан, Овражная урамы буенча 1-72 нчы йорттан, Яшьләр урамы буенча 1-9 нчы йорттан, Гагарин тыкрыгы урамы буенча 1-12 нче йорттан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Сәләнгеш авылы, Гагарин урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Сәләнгеш авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында Колхоз урамы буенча 1-37 нче йорттан, Полевая урамы буенча 1-17 нче йорттан, Горький урамы буенча 1-25 нче йорттан, Гагарин урамы буенча 1-47 нче йорттан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Сәләнгеш авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Сәләнгеш авылы чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Сәләнгеш авылында су белән тәэмин итү объектларының тирә-юнен тәртипкә китерү, ремонтлау һәм төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.
7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы А.Н. Пинин